ГЛАВА БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
Олы МемиАВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

20.11.2015 с. Большие Меми № 1

Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге Советының «2016 елга Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге бюджеты турында» карары проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләү турында

Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын яклау максатларында 2016 елга Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге бюджеты проекты буенча фикер алышуда катнашу өчен "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының "Олы Меми авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 15 статьясы нигезендә гавами тыңлаулар үткәрү юлы белән 2016 елга бюджет проекты буенча фикер алышуда катнашу өчен

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге Советының "2016 елга Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге бюджеты турында" гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Үткәрү датасы һәм вакыты - 2015 елның 2 декабрендә 10.00 сәгатьтә;

2.2. үткәрү срогы - 1 көн;

2.3 үткәрү урыны - Олы Меми авылы, 19 нчы йорт Олы Меми авылы мәдәният йорты бинсында;

2.4. чыгыш ясау хокукы белән җәмәгать тыңлауларында катнашу өчен фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирелгән адрес – Олы Меми авылы, Молодежная ур., 19, Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре Сальцинова А. А. заявка бирергә мөмкин (эш көннәрендә - 8.00 дән 16.00 гә кадәр);

2.5. гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү срогы - 2015 елның 1 декабренә кадәр (тел 36-0-32).

3. Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге башкарма комитетына:

3.1. Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге Советының «2016 елга Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге бюджеты турында» карары проекты буенча һәм гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге Карарда билгеләнгән срокларда гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

3.2.гавами тыңлаулар үткәрү йомгаклары буенча Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге Советына гавами тыңлаулар беркетмәсе, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге бюджеты проектын 2016 елга эшләнеп беткән (үзгәрешләр кертелгән очракта) проект белән тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны, Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге Советы карары проектын «2016 елга Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге бюджеты турында» Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Н.А. Скарлухин